**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Ятмас-Дусай авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2022 елның 02 ноябре** **№26**

**«Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 14 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Шепшеңәр авылы, Мәктәп урамы, 10в йорт адресы буенча урнашкан Шепшеңәр авылы мәчет бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 19 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Шепшеңәр авылы, Мәктәп урамы, 10в йорт адресы буенча урнашкан Шепшеңәр авылы мәчет бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: « укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 3500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Шепшенар авылында су башнясын карап тоту һәм ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- зиратны карап тоту һәм ремонтлау, зират өчен койма (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект - смета документациясен эшләү;

- Шепшенар авылында Мәктәп урамындагы, Урман урамындагы вак таш җәеп юлларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Шепшенар авылы юлларын кардан чистарту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-граниттан язулы мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру;проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

-чишмәне төзекләндерү (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материалны сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ятмас-Дусай авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы: Ф. Х. Гарифуллина